**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 18 февраль № 101

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү (2013 – 2018 еллар)» чаралар планын («юл картасын») раслау турында» 2013 ел, 29 май, 359 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү (2013 – 2018 еллар)» чаралар планына («юл картасына») үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү (2013 – 2018 еллар)» чаралар планын («юл картасын») раслау турында» 2013 ел, 29 май, 359 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 30 сентябрь, 701 нче, 2014 ел, 30 июнь, 450 нче, 2016 ел, 29 гыйнвар, 46 нчы, 2016 ел, 30 декабрь, 1060 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү (2013 – 2018 еллар)» чаралар планына («юл картасына»), аны бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин